КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 ноябрь г.Казань № 936

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү турында» 2024 ел, 30 декабрь, 1268 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү турында» 2024 ел, 30 декабрь, 1268 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 29 апрель, 280 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «инвалид балаларга» сүзләреннән соң «һәм балигъ булган гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

преамбулада «инвалид балаларга» сүзләреннән соң «һәм балигъ булган гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Фенилкетонурия белән авыручы затларга айлык акчалата түләү билгеләргә:

айлык акчалата түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән датага инвалид балаларга Татарстан Республикасында “Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында” 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән балалар өчен яшәү минимумы зурлыгының 50 проценты күләмендә;

айлык акчалата түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән датага балигъ булган гражданнарга Татарстан Республикасында “Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында” 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы зурлыгының 50 проценты күләмендә.»;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Фенилкетонурия белән авыручы затларга айлык акчалата түләү күләме, Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркеменең яшәү

минимумы үзгәргән айдан башлап, гаризасыз тәртиптә яңадан исәпләнергә тиеш. Фенилкетонурия белән авыручы затларга айлык акчалата түләүне бирү яңадан исәпләгәннән соң шулай ук гаризасыз тәртиптә гамәлгә ашырыла.»

2 пунктта «инвалид балаларга» сүзләрен «затларга» сүзенә алмаштырырга;

3 пунктта «инвалид балаларга» сүзләрен «затларга» сүзенә алмаштырырга;

5 пунктта «инвалид балаларга» сүзләрен «затларга» сүзенә алмаштырырга;

6 пунктта «инвалид балаларга» сүзләрен «затларга» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү тәртибе турында нигезләмәдә:

исемендә «инвалид балаларга» сүзләрен «затларга» сүзенә алмаштырырга;

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә фенилкетонурия белән авыручы затларга айлык акчалата түләү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба - айлык акчалата түләү).

2. Айлык акчалата түләү фенилкетонурия белән авыручы балигъ булган гражданнарга яки фенилкетонурия белән авыручы инвалид бала белән яшәүче ата-ананың берсенә (законлы вәкиленә) билгеләнә (алга таба тиешенчә – гариза бирүче, инвалид бала).»

3 пунктта:

өченче абзацка «инвалид балада» сүзләреннән соң «һәм балигъ булган гражданда» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «бала» сүзен «инвалид бала» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта:

өченче абзацта «бала» сүзен «инвалид бала» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалид балага инвалидлык билгеләнү факты турында;»

алтынчы абзацта «бала» сүзен «инвалид бала» сүзенә алмаштырырга;

6 пунктның бишенче абзацында «граждан» сүзен «гаиза бирүче» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин